Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бута авыл Советы

КАРАРЫ

12 май 2020 ел                                                                                    № 115

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 91 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирлеге территориясендәҗирсалымытурында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, 2019 елның 15 августында 23/1-07-2019 номерлы Кама табигатьне саклау прокуратурасының протестын, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2020 елның 17 апрелендәге 140пр номерлы протестын карап,

Бута авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советының2013 елның 25 ноябрендәге 91 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 3 пунктындагы икенче абзацында «авыл җирлегенә» сүзләрен «торак пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. карарның 3 пунктындагы өченче, дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-0,3процентмөнәсәбәтендә торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлеге хокуктагы өлештән тыш) яисәторак төзелеше өчен(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланылу өчен индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);

-0,3 процент мөнәсәбәтендәшәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата;»;

1.3. 3 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге яңа бишенче абзац белән тулыландырырга:

«-0,3 процентмөнәсәбәтендә оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә булудан чикләнгән җир кишәрлекләренә карата;»;

1.4 бишенче, алтынчы абзацларны алтынчы, җиденче абзацлар дип санарга;

1.5. 5 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«-I һәм II грпуппа инвалидлар, балачактан инвалидлар, инвалид балалар, өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган физик затлар эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата.

Салым түләүчеләр - салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салымга ташламалар бирү турында гариза тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы»;

1.6. карарның 6, 7 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.7. карарның 8 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер ай узгач үз көченә керә, 1 пунктның 1.2, 1.6 пунктчаларыннан тыш.

2.1 Әлеге карарның 1 пунктының 1.2, 1.6 пунктчалары 2021 елның 1 январеннән үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

2.2.Әлеге карарның 1 пунктының1.5 пунктчасының гамәли көче 2019 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»ында (PRAVO.TARSTAN.RU) урнаштырырга.

Бута
авыл җирлеге башлыгы Д.Е. Абрамов